# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# «ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

04.02.2015 ел № 57/2

Әҗмәкәй авыл җирлегендә җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Җирле референдум турында» 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Җирле референдум турында» 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, Әҗмәкәй авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2015 елның 02 февралендәге 01 номерлы карары, Азьмушкино авыл җирлеге Советының 2015 елның 02 февралендәге 1/2 номерлы карары, Әҗмәкәй авыл җирлеге уставы нигезендә, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2015 елның 22 мартына якшәмбе көнне Әҗмәкәй авыл җирлегендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе белән берлектә Әҗмәкәй авыл җирлегендә җирле референдумны уздыру турындагы инициативаны җирле референдумның түбәндәге сораулар белән формалаштырырга: «1) 2015 елда Әҗмәкәй авыл җирлеге территориясендә торак урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 100 (йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүләрне кертергә ризамы?

а) Яңа поселогында Үзәк урамда урнашкан күпфатирлы йорт территорияләрен киртәләү - 656250сум;

б) Әҗмәкәй авылының Тукай урамындагы парк территориясен төзекләндерү - 116750сум;

в) Иске Гәрдәле авылы зираты өчен койма - 71500сум;

г) Яңа Сарайлы авылының каты көнкүреш калдыкларын җыю буенча контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү - 41500сум

2) Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм ветераннары, көндезге формада укучы ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар һәм студентлар өчен бер тапкыр бирелә торган түләүне киметергә һәм әлеге категориядәге гражданнар өчен 50 (илле) сум күләмендә аны билгеләргә ризамы?

3. Референдум әзерләүне һәм уздыруны референдум комиссияләренә йөкләргә:

- муниципаль берәмлекнеӊ сайлау комиссиясе;

- участок комиссияләре.

4. Җирле референдумны уздыруга бәйле чыгымнарны Азьмушка авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырырга..

5. Әлеге карарны газетада, җирлекнеӊ мәгълүмат стендларында һәм Тукай муниципаль районы порталында әлеге карар кабул ителгәннән соӊ биш көннән дә соӊга калмыйча бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе М.Г. Фазылҗанов